ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ш.Маннур ур., 72а нче йорт,Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 3 от «29» января 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы73 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2021 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче /И.Я.Хаев/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2021 ел,3 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2021елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле
үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2955,52 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 770,10 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2699,36 |
| **Барлыгы** | 6424,98 |

Җитәкче И.Я.Хаев

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2021 ел, 3 нче санлы
карарына
2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары,
законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 916,93 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2122,51 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 785,70 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2599,84 |
| **Барлыгы** | 6424,98 |

Җитәкче / И.Я.Хаев/